| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ КАЕНСАРСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**КУКМОРСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ КАЕНСАР**<br>**АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

Каенсар авылы

24 сентябрь, 2024ел №27

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023елның 20 ноябрь 31 номерлы Каенсар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Каенсар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 ноябрь 31 номерлы Каенсар авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2025 елда – 1,2 процент; 2026 елда – 1,2 процент; 2027 елда – 1,2 процент гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган Исемлеккә кертелгән урыннарга карата.».

1.2. 2 пунктның 6 нчы пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Исхаков И.Х.